РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ТИМЕРЛЕКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТИМЕРЛЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Чуаш Тимерлеге ав. КАРАР

«10» ноябрь 2021 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чуаш Тимерлеге авыл җирлегендә гражданнар җыенында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Тимерлек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 22 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта Чуаш Тимерлеге авылы, Совет урамы, 58нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Чуаш Тимерлеге авылының Совет урамында, Совет тыкрыгында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2021 елның 24 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Чуаш Тимерлеге авылы, Совет урамы, 58нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Чуаш Тимерлеге авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча, Урман, Үзәк урамында, Лесхоз, Нурлат урамнарында яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

4. Чуаш Тимерлеге авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе халык җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлегенең Чуаш Тимерлеге авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1 гр инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан тыш, 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Авыл җирлеге торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау һәм таш түшәү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru, бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чуаш Тимерлеге авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Тимерлек авыл җирлеге башлыгы В.И. Гаврилов